КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 июнь г.Казань № 513

Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» һәм «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләрен Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауның дәүләт автоном учреждениеләре белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан ш., Маршал Чуйков ур., 54 й. адресы буенча урнашкан Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба - 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе) һәм Казан ш., Ватутин ур., 13 й. адресы буенча урнашкан «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба - Республика клиник неврология үзәге) Республика клиник неврология үзәген 7 нче шәһәр клиник хастаханәсенә кушу рәвешендә, 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе эшчәнлегенең төп максатларын саклап калып, үзгәртеп оештыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе план биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү, шулай ук 7 нче шәһәр клиник хастаханәсен үзгәртеп кору чараларын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында каралган чаралар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

7 нче шәһәр клиник хастаханәсен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

законнар нигезендә үзгәртеп оештыру чаралары аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

ел саен учреждение Уставында каралган төп эшчәнлек нигезендә 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе өчен дәүләт йөкләмәсен расларга;

учреждениеләрне үзгәртеп оештыру тәмамланган көннән алып 30 көн эчендә 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә һәм күзәтү советы составын расларга;

Уставка тиешле үзгәрешләр кертелгәннән һәм 7 нче шәһәр клиник хастаханәсенең күзәтү советы составы расланганнан соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына элегрәк Республика клиник неврология үзәгенә оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәт исемлеген (шул исәптән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт) һәм күчемсез милек объектларына техник документацияне 7 нче номерлы шәһәр клиник хастаханәсенә оператив идарә хокукында беркетү өчен тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

әлеге карарның 3 пунктының җиденче абзацында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген алганнан соң 30 көн эчендә аны оператив идарә хокукында 7 нче шәһәр клиник хастаханәсенә беркетергә;

7 нче шәһәр клиник хастаханәсенә әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә милекне беркеткәннән соң 90 көн эчендә элек Республика клиник неврология үзәгенең даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында булган җир кишәрлекләрен учреждениегә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы аерым булмаган учреждениеләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин